№4
Февраль
2025

# ЧИШМӘ БАШЫ

МБГБУ “Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”

## *Бу санда:*


- *23 февраль – Ватанны саклаучылар көне*
- *Февраль аенда истәлекле даталар*
- *Укучылар иҗаты*
- *Мәктәп тормышы*
- *Ял сәгатьләрендә*





**Хөрмәтле ир-егетләр!**

*Сезне 23 февраль — Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан котлыйбыз.*

*Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү , туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде.*

*Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез.*

*Мөбарәк булсын матур бәйрәмегез!!!*



*Сез бит безгә таяныч һәм ныклы терәк!*
*Сездә генә курку белмәс олы йөрәк!*
*Ир-егетләр, бүген сезне котлар өчен,*
*Күңелләргә тулышкандыр күпме теләк!*

*Сез булганда, аяз булыр күкләребез,*
*Көн кояшлы, айлы булыр төннәребез!*
*Бик кадерле, бик кирәкле, бик тә газиз,*
*Онытмагыз, кемнәрнеңдер кемнәре сез!*

*Кемгәдер ул, кемгә әти, кемгәдер ир,*
*Тормыш йөге сезнең иңдә, сез баһадир!*
*Рәхмәтебез, хөрмәтебез иксез-чиксез!*
*Гел рәхәттә һәм хөрмәттә яшәгез сез!*

*Ир-егетләр, бәйрәмегез котлы булсын!*
*Юлларыгыз, эшләрегез һәрчак уңсын!*
*Тазалыкның ныгын бирсен сезгә Ходай!*
*Янәшәдә булыгыз сез мәңге шулай!*

*Гөлара Шәрипова*

# Февраль аенда истәлекле даталар




**2 февраль** – Сталинград янында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар иткән көн.

Икенче бөтендөнья һәм Бөек Ватан сугышларында бөек борылыш чоры буларак теркәлгән Сталинград кан коешы 1942 елның 17 июлендә башланып китә. 125 көн дәвамында канкойгыч бәрелешләр бара. Һәр урам һәм һәр йорт йөзләгән, меңләгән корбаннар белән яулап алына. Шәһәр җимерелә һәм кирпеч ватыкларыннан, тимер-томыр өемнәреннән торган хәрәбәләргә әверелә. 19 ноябрьдән бөек борылыш башлана: совет гаскәрләре һөҗүмгә күчә. Сталинградны саклап калу гына түгел, фашистларның 300мең кешедән торган дивизиясе дә камап алына һәм юк ителә.

1943 елның 2 февралендә Идел буендагы шәһәр өчен сугышлар совет гаскәрләренең җиңүе белән тәмамлана. Фашистлар Сталинград сугышында 1,5 миллион хәрбиен югалтса, Совет Армиясенең бер миллионга якын солдаты һәм гражданы һәлак була. Шул исәптән, Татарстаннан 22 мең солдат һәм офицер Сталинград өчен барган кан коешларда мәңгелеккә күзләрен йома.



**12 февральдә** Советлар Союзы Маршалы **Василий Иванович Чуйковның** тууына 125 ел (1900–1982).


Ике тапкыр Советлар Союзы Герое маршал Василий Иванович Чуйков Бөек Ватан сугышындагы кискен бәрелешләрнең берсендә үз исемен мәңгегә язып калдырган. Аның 62 нче армиясе 1942 елның көзендә хәрабәгә әйләнгән Сталинградны саклап кала. Соңрак ул җитәкчелек иткән 8 нче Гвардия Армиясе Берлинга барып җитә һәм сугышны җиңү белән тәмамлый. Генерал Чуйков немецлар Гитлерның үз-үзенә кул салуы турындагы хәбәрне ишеткән беренче чит ил кешесе була. Полководец Берлин гарнизонының капитуляциясен кабул итә.



**8 февраль** – **Россия фәне көне.** Ул император Петр Iнең 1724 елның 28 гыйнвары (8 февралендә яңа стиль белән) указы нигезендә төзелгән Россия Фәннәр академиясенә нигез салу датасына туры килә, Россия галимнәре һәм тикшеренүчеләренең казанышларына багышланган, шулай ук фәнни белемнең һәм инновацияләрнең җәмгыять үсеше өчен мөһимлеген ассызыклый. 1999 елның 7 июнендә Россия Федерациясе Президенты Борис Ельцин указы белән гамәлгә куела.



**14 февраль**– күренекле мәгърифәтче-галим, тарихчы, этнограф, тел белгече, әдип **Каюм Насыйриның** (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйровның) тууына 200 ел (1825–1902).



**15 февраль**– җырчы, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Илһам Гыйльметдин улы Шакировның** тууына 90 ел (1935–2019)

**21 февраль** – Халыкара туган телләр көне.

- терапевт, медицина фәннәре докторы, профессор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе **Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегуловның** тууына 140 ел (1885–1966)

**23 февраль** - җырчы, ТАССРның халык артисты **Рәисә Гайсә кызы Билалованың** тууына 100 ел (1925–2003).

### Әтием-ил тоткасы

*Әти! Нинди бөек сүз! Бу сүз үз эченә матурлык, тынычлык, батырлык, көч төшенчәләрен туплаган.*

*Минем әтием - Насыйбуллин Айрат Галимулла улы Балык Бистәсе районы Балтач авылында туган. Әти - гаилә башлыгы. Ул гаиләнең иминлеге, тынычлыгы өчен җаваплы. Әгәр әтием бер генә көн өйдә булмаса да өйдә шомлы, моңсу. Әти якында булганда, мин үземне тыныч хис итәм. Әтием бөтен килеп чыккан авырлыкларны чишә, авыр чакларда юата.*

*Әтиләр ил сакчылары һәм илебезнең терәге дә булып торалар. Илебезнең тынычлыгы, иминлеге өчен зур көчләрен куялар. Шуңа күрә без тынычлап йоклыйбыз, сулыйбыз һәм яшибез. Әти-әниле бала дөньяда иң бәхетле кеше. Әти-әнине сакларга кирәк. Үз әти-әниеңне чит кешеләр берничек тә алыштыра алмыйлар. Алар - бердәнбер.*

*Минем әтием кечкенәдән бик талантлы, уңган бала булган. „Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз“, - дип әйтәләр. Чыннан да, дөрес сүзләр. Әтием бик тәмле пешерә, баянда һәм гитарада уйный белә. Минем дә әтием шикелле уңган буласым килә.*

*Иң көчле, батыр һәм куркусыз кеше дигәндә дә һәрвакыт әтиемне күзаллыйм. Мин әтием белән бик горурланам!*

*Әти безне орышса да, яратып кына әйтә. Шул рәвешле безне ”акылга“ өйрәтергә тели ул.*

*Мин әтиемне бик нык яратам. Ул минем өчен бик кадерле кеше!*

**Раяна Насыйбуллина**, 6 нчы сыйныф

---

### Әтиебез – күз нурыбыз

*Әти, әтием, әткәем... Нинди матур һәм яхшы сүзләр! Әйе, якын һәм матур, чөнки бу сүздә бөеклек, батырлык, җылылык һәм тынычлык. Әти! Бу өч хәрефтә никадәр җаваплылык, тапкырлык, ышаныч. Әйе, әтиләр алар – тормышыбызның тоткасы.*

*Минем әтием – Бикбаев Рәфкать Ясәви улы. Ул 1975 нче елның 9 нчы маенда Түбән Курса авылында туган. Авылыбыздагы мәктәпне тәмамлагач, 18 яшендә армия сафларына алына. Ул Анапа шәһәрендә 6 ай буе моторчы булырга укый. Аннан соң аны Ленинград өлкәсенә чик буе сакчысы итеп билгелиләр. Карелиягә дә күчергәннәр. Әтием анда бик күп дуслар тапкан. Алар Фин култыгында хезмәт иткәннәр. Әтием Санкт – Петербург, Выборг, Приморье һәм башка шәһәрләрдә булган.*

*Армия әтине җитез, көчле һәм мөстәкыйль булырга өйрәткән. Әтием әйтүенчә, элек армиягә бармый калу егет өчен хурлык дип саналган. Армиядә хезмәт итеп кайткан егетне генә чын ир дип санаганнар. Әтием шуның белән горурлана.*

*Бүгенге көндә дә Ватанны, илне саклау – һәр ир-егетнең бурычы. Алар да әтием кебек солдат һөнәрен яратсыннар, ил сакчылары булу белән горурлансыннар иде.*

**Бикбаева Руфинә,** 7 нче сыйныф

---

### Әтием — горурлыгым!

*Минем әтием — тормышымдагы бик якын һәм кадерле кешем. Әтием минем өчен батыр да, акыллы да, көчле дә.*

*Әтиемнең исеме - Булат. Ул Арча балалар сәнгать мәктәбендә баян һәм вокал укытучысы булып эшли, балаларны музыка серләренә өйрәтә. Әтием үз эшен бик ярата, аңа бөтен күңелен биреп эшли.*

*Минем әтием тырыш, сабыр, олы йөрәкле һәм кешелекле. Ул һәрвакыт акыллы киңәшләр бирә, кирәк чакта ярдәм итә. Без һәрчак әтиебезнең яратуын тоябыз. Ул безнең өчен барысын да эшләргә әзер.*

*Әтием белән бергә вакыт үткәрү миңа зур бәхет. Без күп эшләрне бергә башкарабыз, әтием мине төрле һөнәрләргә өйрәтә, чөнки егет кеше барысын да эшли белергә тиеш. Ул миңа тормыш турында бик күп кызыклы хәлләр сөйли, дөньяны танырга ярдәм итә.*

*Әтием – минем өчен үрнәк. Мин аның кебек акыллы, тырыш, кешелекле булырга тырышам.*

*Әтиемә зур рәхмәт әйтәсем килә! Мин аны бик яратам һәм аның белән горурланам!*

**Гайнуллин Шәфәгать,** 5 нче сыйныф

---

### Әтием - кадерлем!

*Җир йөзендә иң якын кешеләр – әти-әниләр. Әни үзенең назын бирсә, әти һәр яктан терәк булып тора. Әтиләрнең канаты астында үзеңне көчле һәм иркен хис итәсең.*

*Минем әтием дә бик яхшы, олы җанлы, әйбәт әти. Ул-Гатауллин Раил Фанур улы Түбән Курса авылында туа. Авылыбыздагы мәктәптә укый, аны тәмамлагач, Үрнәктә шофёрлыкка укый. 1991нче елда Совет Армиясе сафларына алына, Казанда милиционер булып хезмәт итә. Армиядән кайткая, әти башта авылыбызда шофёр булып эшли, аннан тимер юл эшенә күчә. Хәзерге көнгә кадәр шул эшендә эшли.*

*«Армия – егетләрдән чын ирләр ясый торган мәктәп ул. Ватан өчен җаваплылыкны да шунда тәрбияилиләр», – дип сөйли ул.*

*Гаиләдә иң зур кеше, баш кеше – әти. Чөнки ул гаиләнең барлык башка кешеләре турында кайгырта, җилдән, яңгырдан саклый. Ул - өйнең терәге, өйнең генә түгел әле, әти кеше Ватанның ныклы таянычы.*

*Әти хәзерге көндә әни белән өч бала тәрбияләп үстерә. Бүгенге көндә һәр баланың да әтисе булсын һәм алар да үзләренең әтиләре белән горурлансыннар иде.*

**Гатауллина Ризәлә**, 7 нче сыйныф



# Мәктәп тормышы

Мәктәбебез укучылары Ватанны саклаучылар көненә багышланган **"Солдатка хат" Бөтенроссия акциясе**нә кушылдылар. Һәр юлда рәхмәт сүзләре, солдатларга ихлас күңелдән изге теләкләр яңгырый. Туганнарыннан, ә кайчакта бөтенләй таныш булмаган кешеләрдән килгән хәбәр солдатның күңелен авыр сугыш көннәрендә җылытыр, безнең солдатларга туган якларыннан котлаулар алу күңелле булыр дип уйлыйбыз!



Итоговое собеседование по русскому языку

2025 елның 12 февралендә **рус теленнән йомгаклау әңгәмәсе** узды. Ул дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелүнең мәҗбүри шарты булып тора һәм сөйләм күнекмәләрен тикшерүгә юнәлдерелгән. 9 нчы сыйныф укучылары барысы да бу беренче сынауны уңышлы үтте һәм төп дәүләт имтиханына юллама алды. Уңышлар сезгә, чыгарылыш сыйныф укучылары!



2025 елның 14 февралендә Урта Курса авыл җирлегендә капитан Айрат Галәветдинов исемендәге «Юнармия» һәм «Җиңү волонтерлары» отрядлары әгъзалары катнашында «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел»юбилей медальләрен тапшыру тантанасы булды. Арча муниципаль районы башлыгы Нуриев Илшат Габделфәрт улы 3 тыл хезмәтчәненә медальләр тапшырды.

15 февраль – шагыйрь **Муса Җәлилнең туган көне**. Муса Җәлил – татар халкының сөекле улы, шигырьләре белән фашизмга каршы аяусыз көрәш алып барган бөек шагыйрь. Аңа 1956 елда Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул шулай ук әсирлектә язган «Моабит дәфтәрләре» җыентыгы өчен Ленин премиясенә лаек була.

5-6 сыйныф укучылар белән шагыйрьнең иҗаты, тормышына багышланган " Үз уенң"дигән интеллектуаль уен уздырылды.





Безнең мәктәптә мөһим вакыйга – **Ватанны саклаучылар елын ачу** тантанасы булды. Чарага МХОда катнашучылар һәм сугышчы-интернационалист, Әфган сугышында катнашучы Садыйков Фәнис Турис улы чакырылган иде. Сәламләү сүзләре белән мәктәп директоры Яруллин Р. Р. һәм авыл җирлеге башлыгы Вафина Р. Р. чыгыш ясадылар. Башлангыч сыйныф укучылары, Айрат Галәветдинов исемендәге Юнармия һәм «Җиңү волонтерлары» отрядлары әгъзалары вокаль һәм хореографик номерлар күрсәттеләр, кунакларыбызны һәм ир-егетләрне бәйрәм белән котладылар.

21 февраль көнне мәктәбебезнең спорт залында 5-9 сыйныф егетләре катнашында Ватанны саклаучылар көненә багышланган **"Ягез әле, егетләр!"** спорт уены үтте. Ярыш мавыктыргыч та, шул ук вакытта киеренке дә иде-көчле көндәшләр ярышты бит, ә иң көчлесе җиңәргә тиеш иде... Җанатарлар үз командалары өчен борчылды. Ярышлар чын спорт, сәламәтлек бәйрәменә әверелде! Бәйге йомгаклары буенча дуслык җиңде!






21 февраль көнне мәктәптә Халыкара Туган тел көненә багышланган кичә үткәрелде. Туган тел-аралашу чарасы гына түгел, ә бәлки безнең мәдәни мирасыбызның һәм тарихыбызның мөһим өлеше дә. Татар һәм рус теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә укучылар викторина сорауларына, табышмакларга җавап бирделәр, Биремнәр төрле милләт биюләре, җырлар белән аралаштырып алып барылды. Кичә Г.Тукайның «Туган тел» җырын күмәк башкару белән тәмамланды.

Мәктәбебез укучылары районыбызда узган 3 чаңгы ярышында (Сезонны ачу ярышы, Фәнил Гарәфиев истәлегенә үткәрелгән район һәм республика күләмендәге ярышлар) актив катнашып, команда белән призлы II урыннарга лаек булдылар. Укучыларны һәм җитәкчеләре Минһаҗев Марсель Вадутовичны котлыйбыз! Молодцы!



## Сүзләр эзләү

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ш | Х | С | Я | П | К | А | М | Ю | Я | Т | П | Ъ | Ю | Ь |
| И | А | К | Ы | Г | Л | Я | С | А | А | Ъ | Г | Т | З | П |
| П | Р | Э | Я | М | К | И | А | Т | К | Г | Н | А | Ф | Й |
| С | Р | П | В | М | Ч | Щ | А | А | Ы | Ү | Я | Ж | Щ | П |
| И | О | Х | Ъ | Б | Э | Р | З | Й | З | Ъ | Б | Щ | Я | А |
| Р | К | М | Ф | Г | С | Ч | Р | Б | Ц | В | К | И | С | М |
| У | О | Ж | Б | Т | М | А | Ә | О | Й | А | Н | К | У | Ы |
| С | Ш | Х | А | Р | К | К | Я | Я | З | А | Е | Ж | С | Р |
| И | У | Н | В | Б | С | И | И | А | М | Е | Ы | Щ | В | Ж |
| Я | Э | Л | В | Т | К | Н | Х | Л | Р | Ь | П | Э | Ы | Ч |
| Р | А | Ь | А | Р | А | С | А | К | И | Ы | Х | З | Ц | Г |
| Д | Ш | Н | Ө | Т | Т | Ю | У | К | О | Ф | С | Н | М | Ь |
| О | В | Т | И | А | Д | В | Т | У | П | М | З | И | Ц | Ф |
| Ф | С | Р | Н | В | Х | Ш | Ъ | О | П | В | Х | О | М | К |
| Э | Б | Ю | Д | Е | З | Т | Ы | Й | О | Ж | Ы | Н | В | Т |

МИСЫР
РУСИЯ
ТАТАРСТАН
АЛМАНИЯ
ТӨРКИЯ
ГЫЙРАК
КАЗАХСТАН
БРИТАНИЯ
ҮЗБӘКСТАН



## *Мәзәкләр*



*Әтисе –улына:*
*-Менә мин кичә 5 мең таптым да полициягә илтеп бирдем, ә син акча тапсаң нишләр идең?*
*-Мин дә синең кебек алдашыр идем, әти.*

***

*-Кем беренче такта янына чыга? Шуңа бер балл югарырак куям.*
*-Мин чыгам, - ди Вәли, - куегыз өчлегезне.*

***

*-Вәли, ни өчен синең өйгә эшеңне гел әтиең эшли?*
*-Әнинең вакыты юк.*

*-Кичә глобус алдым. Сәяхәт итәчәкмен!*
*-Кайдан шулкадәр акча алдың?*
*-Глобус кыйммәт тормый ул.*

***

*-Улым, әйдә бәрәңге казырга барабыз!*
*-Әти, иртәнге өч бит!*
*-Улым, тор инде, бәрәңге казыйсы бар.*
*-Әти, безнең бәрәңге бакчабыз юк бит!*
*-Бәрәңге бакчабыз булмаса да, бәрәңге ашыйсы килә бит!*

**Сәхифәне әзерләде:**
Башлангыч сыйныф укытучылары Минһаҗева Ч.М. һәм Насыйбуллина Ф.К.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:**
422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт
**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru

**Социаль челтәр бите:**
https://vk.com/ 77arsk_srkorsa